ШИМБӘ
6 ГЫЙНВАР
1940 ел
№ 5 (5805)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

ТЕРЛЕКЧЕЛЕК ПРОБЛЕМАСЫН УҢЫШЛЫ ХӘЛ ИТҮ ӨЧЕН

ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм СССР Халык Комиссарлары Советы „Колхозларда җәмагат терлекчелеген үстерү чаралары турында“ карар чыгарып, социалистик терлекчелекне үстерү юлында колхозларга гаять зур һәм көчле хәрәкәт программасын бирделәр. Бу карар колхозчылар арасында политик һәм производство активлыгының яңа күтәрелешен тудырды. Карар чыкканнан соң социалистик терлекчелек искиткеч тизлек белән үсә башлады. Колхозлар яңа фермалар оештыру, иске фермаларны тулыландыру эшенә ныклап керештеләр.

1939 нчы елда Татарстан АССР колхозларында гына да яңадан 1.226 товарлыклы-сөтчелек фермалары, 734 сарык асраучылык фермалары һәм 246 дуңгыз асраучылык фермалары оештырылды. Электән яшәп килгән фермаларны тулыландыру өчен колхозлар 6 меңнән артык төрле терлек сатып алдылар. Хәзер бездә колхозларның күпчелегендә инде икешәр һәм өчәр терлекчелек фермалары бар. Хәзер бер нинди дә фермасы булмаган колхозлар бөтенләй юк дип әйтерлек.

1939 нчы елгы Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсе һәм 1940 нчы елда аңар катнашу хокукына ирешү өчен киң күләмдә барган һәм бара торган көрәш бу уңышларга ирешүдә гаять зур урын тотты. Социалистик терлекчелек алдынгылары күргәзмәдән кайткач үз колхозларына, үз фермаларына терлекчелекне үстерү буенча бик күп яңалыклар кертеләр.

Күп кенә районнарыбызның һәм меңнәрчә алдынгыларыбызның терлекчелек өлкәсендә 1939 нчы елда ирешкән уңышлары бигрәк тә сокланырлыклар. Октябрь районы 1939 нчы елда ат үрчетү, мөгезле эре терлек, дуңгыз, сарык һәм җәнлек үрчетү буенча дәүләт тарафыннан бирелгән планны 100 процент, кошкорт үрчетү планын 103 процент, йорт куяннары үрчетү планын 158 процент үтәде. Калинин районында, 1935 нче елгы белән чагыштырганда, 1939 нчы елда атлар саны 142 процент, сыерлар саны 193 процент, сарыклар саны 265 процент, дуңгызлар саны 313 процент артты.

Колхозларның терлекчелектән килә торган доходлары да күбәйде. Калинин районының Пучы авыл советына караган „1—Май“ колхозы 1939 нчы елда терлекчелек фермасыннан 70 мең сум доход алды. Шул ук районның Алексеевский авыл советына караган „Правда“ колхозы фермасы 57 мен сум доход бирде. Кайбыч районының Олы Кошман авылы, „Активист“ колхозы фермасының (мөдире иптәш Шаһидуллин) 1938 нче елгы акчалата доходы колхозның шул елгы акчалата доходының 37,8 процентын тәшкил иткән булса, 1939 нчы елда 60 процентын тәшкил итте.

Терлекчелекне күтәрү буенча мондый уңышлы фактларны һәрбер районда күпләп табарга мөмкин. Бу уңышлар бөтенесе дә партиябезнең тарихи XVIII нче съезды тарафыннан куелган гаять зур бурычларны хәл кылуга хезмәт итәләр, өченче бишьеллыкта терлекчелек проблемасының тулысынча һәм уңышлы хәл ителәчәгенә ышанычыбызны тагын да ныгыталар.

ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм СССР Халык Комиссарлары Советы „Колхозларда җәмагат терлекчелеген үстерү чаралары турында“гы карарның үтәлешенә 1939 нчы елның сентябрендә тикшерү үткәреп, бу турыда махсус карар чыгарганнар иде. Бу карарда урыннардагы совет һәм партия оешмаларына 1939—1940 нчы елда терлекләрне кышлатуның колхозларда җәмагат терлекчелеген тагын да үстерү һәм ныгыту эшендә хәл иткеч эш икәнлеген истә тотарга тәкъдим ителгән иде.

Партиябезнең һәм хөкүмәтебезнең бу күрсәтмәсен тормышка ашыру өчен чын күңел биреп эшләгән колхозлар, фермалар быел терлекләрне кышлатуны тулы хәзерлек белән каршы алдылар һәм терлекне кышлатуны уңышлы итеп алып баралар. Бу мәсьәләдә Кайбыч районының „Активист“ колхозы эше бик күп фермаларга үрнәк була ала. Бу фермада терлекләрне кышлату буенча барлык уңайлы шартлар булдырылган. Биредә терлеккә карата иясезлек тәмам бетерелгән. Хезмәт фермада эшләүчеләрне терлекләрдән мул продукция алу белән турыдан-туры кызыксындырырлык итеп оештырылган. Тупас һәм концентрат азыклардан дөрес һәм экономия белән файдалануга, тупас азыкларны эшкәртеп ашатуга аеруча җидди игтибар бирелә.

Азыкка экономия ясауның гомумән, ә быел бигрәк тә, әһәмияте чиктән тыш зур. Ләкин кайбер районнарда бу эшкә һаман да әле тиешенчә әһәмият бирелми. Күп кенә район һәм колхоз җитәкчеләре моннан элеккеге еллардагы кимчелекләрнең быел да кабатлануына юл куялар. Мисаль өчен Биләр районы җитәкчеләрен алырга мөмкин. Алар терлек азыклары җитәрлек түгел, дип адым саен зарланалар, ә шул ук вакытта булган азыктан рациональ файдалануны большевикларча оештыру турында конкрет бер эш тә эшләмиләр. Тупас азыкларны эшкәртеп ашату бу районның бары өч кенә колхозында оештырылган. „Кызыл партизан“ колхозында (председателе Газизов) терлек азыкларын базарга чыгарып сату, колхоз терлекләрен азыксыз калдыру кебек фактларны Биләр районы җитәкчеләре „күрмиләр“.

Кышлату чорының терлекчелектә иң җаваплы чор булуын бер вакытта да истән чыгарырга ярамый. Терлек азыкларын әрәмшәрәм итүчеләргә карата ныклы чаралар күрелергә тиеш.

Терлекләрне кышкы чорда тәрбия итү буенча алдынгыларның уңышлы тәҗрибәләрен башкаларга да күчерүне оештырырга кирәк. Терлекчелекне үстерү өчен барган социалистик ярышны тагын да киңрәк җәелдереп һәм аңар партия, совет һәм комсомол оешмаларының җанлы җитәкчелеген булдырып, барлык колхозларда да терлекләрнең кышны иң яхшы шартларда, тук һәм исән үткәрүләре тулысынча тәэмин ителергә тиеш. Эшне большевикларча оештырганда моңар һәрбер фермада, һич сүзсез, ирешергә мөмкин һәм ирешергә кирәк.

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

Н. Д. Доронин, А. Д. Доронин һәм В. Д. Доронин иптәшләрне бүләкләү турында

СССР ның оборона сәләтен ныгыту эшендәге уңышлы эшләре һәм инициативалары өчен—бүләкләргә:

„Почет билгесе“ ордены белән

1. МИИТ студенты Николай Дмитриевич Доронинны.

„Аеруча хезмәт күрсәткән өчен“ медале белән

1. Кызыл армеец Анатолий Дмитриевич Доронинны.

2. Горбунов исемдәге заводның инженеры Владимир Дмитриевич Доронинны.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателенең урынбасары А. БАДАЕВ.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре А. ГОРКИН.

Москва, Кремль.
4 гыйнвар, 1940 ел.

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАСЫ

4 нче гыйнварда фронтта әйтерлек бер нәрсә дә булмады.

РАЙОН СОВЕТЛАРЫНЫҢ БЕРЕНЧЕ СЕССИЯЛӘРЕ

ӘЛКИ РАЙОНЫ

БАЗАРЛЫ МАТАК, 4 гыйнвар. (ТатТАСС). Хезмәт ияләре депутатларының Әлки район Советының беренче сессиясе булып үтте.

Трибунага иң карт депутат иптәш Сиделкина күтәрелә. Сессия утырышын ачканда, ул дөньяда иң демократик Конституцияне иҗад итүче иптәш Сталинны кайнар рәвештә котлый, коммунистларның һәм партиясезләрнең Сталинчыл блогының яңа җиңүе турында сөйли.

Аннары, депутат иптәш Сиделкина беренче сессиянең беренче утырышын ачык дип игълан итә. Сессияне алып бару өчен председатель итеп бер тавыштан депутат Шәйхеттинев, секретарь итеп депутат Сираев иптәшләр сайлана. Сессия 3 кеше составында мандат комиссиясе сайлый. Депутат Хураскина, Хужин, Бәдерттинев һәм Шәрипов иптәшләрнең тәкъдиме буенча район Советының башкарма комитеты составы сайлана. Башкарма комитет председателе итеп Татарстан АССР Верховный Советы депутаты һәм район советы депутаты иптәш Зайнуллин, аның урынбасары итеп депутат Яруллин, секретарь итеп депутат Буланкин сайлана.

Сессия башкарма комитет бүлекләрен: финанс, халык мәгарифе, сәламәтлек саклау, сәүдә, җир, юл төзелеше, гомуми бүлек, план комиссиясе һәм кадрлар секторы төзү эшенә керешә. Аннары, бүлек мөдирләре раслана. Аннан соң сессия район Советының даими комиссияләрен сайлады.

Мандат комиссиясенең докладыннан соң Әлки район Советының беренче сессиясе үзенең эшен тәмам итте.

ЮДИНО РАЙОНЫ

ЮДИНО, 5 гыйнвар. (ТатТАСС). 4 нче гыйнварда Юдин исемендәге клубта хезмәт ияләре депутатларының Юдино район Советының беренче сессиясе ачылды. Клубның залы халык тарафыннан сайланучылар—хезмәт ияләре депутатлары белән тулы иде. Алар арасында районның иң яхшы кешеләре: Юдино депосының бөтен Казан тимер юлына билгеле булган машинисты, Ленин ордены белән бүләкләнгән Митрофан Григорьевич Крылов, орденлы укытучылар Ольга Никаноровна Матвеева һәм А. А. Ключникова, Казан тимер юлының Юдино станциясе политбүлеге начальнигы Михаил Абрамович Блюменцев, астрономия обсерваториясе профессоры Дмитрий Яковлевич Мартынов, Юдино больницасы врачы А. А. Демьяновский, авыл хуҗалыгы күргәзмәсенә катнашкан Буденный исемендәге колхоз председателе иптәш Тарасов һәм башкалар бар.

Трибунага депутат М. Г. Крылов күтәрелә. Ул Юдино район Советының беренче сессиясен ачуны Киндерле авыл Советы председателе, карт депутат Степан Филипович Евружихинга тапшыру турында тәкъдим кертә.

Депутатлар бу тәкъдимне бердәм кул чабулар белән каршы алдылар.

Депутат иптәш Евружихин сессияне ачканда кыска, ачык речь сөйли.

Сессияне алып бару өчен председатель итеп бер тавыштан депутат Блюменцев, секретарь итеп депутат орденлы О. Н. Матвеева иптәшләр сайланалар.

Сессиянең беренче утырышы зур күтәренкелек белән үтте. Сессия өч кеше составында мандат комиссиясен һәм 9 член составында башкарма комитетны сайлады. Башкарма комитетның председателе итеп депутат В. Ермишин, урынбасары итеп „Маяк № 1“ колхозы председателе депутат Х. Г. Гәрәев иптәшләр бер тавыштан сайланалар. Башкарма комитет членнары арасында РСФСР Верховный Советы депутаты П. И. Захаров, Юдино депосы машинисты ярдәмчесе стахановчы комсомолка Е. Д. Пашина иптәшләр бар. Башкарма комитетның бүлекләре төзелде һәм даими комиссияләр оештырылды.

Озакка сузылган көчле алкышлар астында сессия бөек Сталинга котлау хаты кабул итте.

Үзенең икенче утырышында сессия мандат комиссиясенең докладын тыңлады.

ТЕЛӘЧЕ РАЙОНЫ

ТЕЛӘЧЕ, 5 гыйнвар. (ТатТАСС). ВКП(б) райкомының утырышлар залына районның алдынгы кешеләре җиналды. Монда халык тарафыннан сайланган кешеләр—район Советы депутатлары һәм стахановчылар, колхозларның, МТС, предприятиеләрнең һәм җәмагат оешмаларының вәкилләре. Депутат иптәш Хәйбуллинның тәкъдиме буенча Теләче район Советының беренче сессиясен урта мәктәп укытучысы, орденлы депутат иптәш Антонина Михайловна Макарова ача.

— Халык тарафыннан сайланган булу—ул иң җаваплы, иң мактаулы эш. Халыкка хезмәт итүчеләр сыйфатында без аның теләген намус белән үтәргә, аның ышанычын акларга тиешбез. Без халык өчен Ленин кебек һәм иптәш Сталин кебек эшләргә тиешбез,—диде, иптәш Макарова.

Сессияне алып бару өчен председатель итеп депутат Камал Дәүләтшин, секретарь итеп депутат Новиков иптәшләр сайлана.

Көн тәртибе кабул ителгәннән соң, сессия Теләче урта мәктәбе укучыларының һәм пионерларының беренче ярты елда ирешкән уңышлары турында, МТС директоры иптәш Шәймәрдәневнең тракторларга ремонт планының үтәлүе турында һәм „Кызыл Янбулат“ колхозы председателе иптәш Гәрәевнең колхозның чәчүгә хәзерлеге турында рапортларын тыңлады.

Мандат комиссиясе председателе депутат иптәш Заманов барлык 34 депутатның район советына Татарстан АССР Конституциясе һәм хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлаулар турындагы Положение нигезендә сайланган булуларын хәбәр итте.

Сессия 10 кеше составында район советының башкарма комитетын сайлады. Башкарма комитетның председателе итеп депутат Солтанов, урынбасары итеп депутат Чукуров, секретарь итеп депутат Чумадуров иптәшләр сайланды.

Сессия башкарма комитетның 8 бүлеген, план комиссиясен һәм кадрлар секторын төзеде. Депутатлар район башкарма комитетының план комиссиясе, халык мәгарифе бүлеге һәм сәүдә бүлеге эшендәге җитешсезлекләрне кискен рәвештә тәнкыйтьләделәр.

БИЕКТАУ РАЙОНЫ

БИЕКТАУ, 5 гыйнвар. (ТатТАСС). 4 нче гыйнварда Биектау район Советының беренче сиссиясе тантаналы обстановкада үтте. Хохлово авылының тулы булмаган урта мәктәбе укытучысы, орденлы депутат иптәш Елизавета Трофимовна Липина сессияне ачканда сөйләгән речендә болай диде:

— Депутат иптәшләр! Сайлаулар көне—24 нче декабрь—бөтен халык бәйрәме булды. Ватаныбызның хезмәт ияләре бөек Ленин—Сталин партиясенә, даһи Сталинга үзләренең мәхәббәтләрен һәм чын күңелдән бирелгәнлекләрен тагын бер тапкыр күрсәттеләр. Алар коммунистларның һәм партиясезләрнең Сталинчыл блогы кандидатларына тавыш бирделәр. Алар Ватаныбызның иң яхшы улларына һәм кызларына тавыш бирделәр. Депутат иптәшләр! Халык тарафыннан сайланган булудан да, аңа хезмәт итүдән дә югары бер нәрсә дә юк.

Иптәш Липинаның речьннән соң депутат иптәш Соломатинның тәкъдиме буенча сессияне алып бару өчен председатель итеп депутат Ф. Х. Ибраһимов, секретарь итеп депутат А. Е. Николаев иптәшләр бер тавыштан сайланалар. Аннары, депутат иптәш Строителевнең тәкъдиме буенча сессиянең көн тәртибе раслана.

Депутат иптәш С. Е. Кузнецовның тәкъдиме буенча хезмәт ияләре депутатларының район советы башкарма комитетының председателе итеп депутат Федор Васильевич Кашицин, урынбасары итеп депутат Әминә Гинияят кызы Мирзабекова, секретарь итеп депутат Х. Х. Әхметов иптәшләр сайлана.

Аннары сессия башкарма комитетның бүлекләрен төзеде һәм бүлек мөдирләрен раслады. Сессия даими комиссияләрне: бюджет, сәүдә, сәламәтлек саклау, оборона-физкультура һәм мәктәп комиссияләрен оештырды.

2 нче тегү фабрикасының 4 нче цехында өч төрле спец машинада эшләүче стахановчы Т. Кржеманова айлык планны системалы рәвештә арттырып үтәп килә. Мәсәлән, октябрьдә 162 процент, ноябрьдә 171, декабрьдә 188 һәм 2 нче гыйнвар көнне 185,8, 3 нче гыйнвар көнне 162 процентка үтәде.

И. Галиев фотосы.

МАМАДЫШ ШӘҺӘР СОВЕТЫНЫҢ БЕРЕНЧЕ СЕССИЯСЕ

МАМАДЫШ, 5 гыйнвар (ТатТАСС). 2—3 нче гыйнварда культура йортында хезмәт ияләре депутатларының Мамадыш Шәһәр Советының беренче сессиясе булды. Сессияне карт депутат Иван Алексеевич Березин ачты. Сессияне алып бару өчен председатель итеп депутат Белоглазов, секретарь итеп Короткова иптәшләр сайланды.

Депутат иптәш Белобородованың тәкъдиме буенча сессия 5 мәсьәләдән торган көн тәртибен кабул итте. Аннары сессия 5 депутат составында мандат комиссиясе сайлады.

Икенче утырышта депутатлар группасының тәкъдиме буенча 9 депутаттан башкарма комитет сайланды. Сессия башкарма комитетның председателе итеп депутат Аркадий Михайлович Семенов, урынбасары итеп депутат Неумоин, секретаре итеп депутат Хәбирә Гыйсматуллина иптәшләрне сайлады. Сессия бүлек мөдирләрен бер тавыштан раслады һәм 5 даими комиссия: бюджет, мәктәп, сәламәтлек саклау, сәүдә һәм шәһәр төзелеше комиссияләре төзеде.

Аннары сессия мандат комиссиясе председателе депутат иптәш Матвеичеваның докладын тыңлады.

ЯҢА БАШКАРМА КОМИТЕТ ЭШКӘ БАШЛАДЫ

ЗЕЛЕНОДОЛЬСК, 5 гыйнвар. (ТатТАСС). Зеленодольск Шәһәр Советының башкарма комитеты практик эшкә башлады. 4 нче гыйнварда башкарма комитетның беренче утырышы булды. Бу утырышта гыйнвар өчен эш планы расланды, шәһәр Советының кадрлар секторы төзелде, Е. Г. Мачинаның 7 нче баласы өчен пособие бирү турындагы гаризасы каралды. Аның соравын канәгатьләндерергә карар бирелде.

Утырышта шәһәр Советының эшләрен тапшыру һәм кабул итеп алу турындагы мәсьәлә тикшерелде. Башкарма комитет шәһәр Советы бүлекләренең эшен тикшерүгә даими комиссияләрне тартырга карар бирде. Алар шәһәр Советында эшнең торышы турында 26 нчы гыйнварга үзләренең нәтиҗәләрен бирәчәкләр. Аннары шәһәр Советы бүлекләренең кредитлары белән эш итүчеләр турындагы мәсьәлә хәл ителде. Ахырда башкарма комитет Татарстан АССР ның 20 еллыгына хәзерлек турындагы мәсьәләне тикшерде һәм 20 еллыкны үткәрү өчен 12 кешедән комиссия төзеде.

КВЖД ӨЧЕН СОҢГЫ ВЗНОС КЕРТЕЛДЕ

1939 нчы елның 31 нче декабрендә булган Совет—Япон килешүе буенча Япония хөкүмәте Манчжоу-Го хөкүмәтенең КВЖД өчен соңгы взносны шушы елның 4 нче гыйнварында кертүен тәэмин итәргә тиеш иде.

Бүген, 1940 нчы елның 4 нче гыйнварында, иртән 11 сәгатьтә Манчжоу-Го илчелеге вәкилләренең катнашы белән Японияенең промышленность банкысы Совет хөкүмәтенең Токиодагы тулы хокуклы илчесе иптәш Сметанинга 5.809.565 иена 81 сена күләмендәге сумага чик бирде.

СССР ның Токиодагы тулы хокуклы илчесе иптәш Сметанин банкка Манчжоу-Гоның 5.981.625 иена күләмендәге сумага казначейлык обязательствосын тапшырды һәм югарыда күрсәтелгән сумага банктан чик алуы турында Манчжоу-Го илчесенә расписка бирде, ә банк илчегә югарыда күрсәтелгән казначейлык обязательствосының тапшырылганлыгы турында расписка бирде.

Шулай итеп, КВЖД өчен соңгы взносны түләү турында 1939 нчы елның 31 нче декабрендә төзелгән Япон—Совет килешүенең беренче пункты срогында үтәлде. (ТАСС).

ЯПОНИЯ СӘҮДӘ ДЕЛЕГАЦИЯСЕНЕҢ МОСКВАГА КИЛҮЕ

4 нче гыйнварда Москвага Японияенең Швециядәге гадәттән тыш илчесе һәм тулы хокуклы министре Мацусима Сикао әфәнде җитәкчелегендә Японияенең сәүдә делегациясе килде. Мацусима Сикао әфәнде белән берлектә Танака Мицуо, Митани Сидзуо, Кобаяси Сатору һәм Михо Микитаро әфәнделәр килделәр.

Төньяк вокзалда аларны Тышкы Сәүдә Наркомы урынбасары иптәш Ю. М. Каганович, СССР ның Япониядәге сәүдә илчесе иптәш Л. А. Разин, Наркоминделның протоколлар бүлеге мөдире иптәш В. Н. Барков, Наркомвнуторгның договорлар бүлеге начальнигы хезмәтләрен үтәүче иптәш Д. Д. Мишустин, СССР ның Япониядәге сәүдә илчесенең урынбасары иптәш П. Г. Вакуленко, Наркомвнешторгның протоколлар бүлеге начальнигы иптәш С. А. Вшивков, Наркомвнешторгның Япония буенча референты иптәш М. Д. Яшников һәм Япония илчесе Того әфәнде җитәкчелегендә Япония илчелеге составы каршы алдылар.

ПРОПАГАНДА ҺӘМ АГИТАЦИЯ РАБОТНИКЛАРЫНЫҢ ӨЛКӘ КИҢӘШМӘСЕ

Җитәкче работник үз өстендә эшләүнең үрнәген күрсәтергә тиеш

ИПТӘШ ИСХАКОВ РЕЧЕННӘН

(Кызыл Армия районы)

Безнең районда ВКП(б) тарихын 378 кеше өйрәнә. Бу, әлбәттә аз. Өйрәнүчеләр арасында үзләренең политик белемнәрен күтәрү өстендә канәгатьләнерлек эшләмәүче иптәшләр бар. Бигрәк тә, җитәкче работниклар тарихны өйрәнүдә артта баралар.

Практика шуны күрсәтә: әгәр җитәкче работниклар, активистлар китап өстендә яхшы эшләсәләр, безнең түбәнге кадрларыбыз да аларга ияреләр. Шулай булгач, марксизм-ленинизм белемен өйрәнүне активтан, җитәкче работниклардан башларга кирәк.

Безнең райком аппаратында 20 коммунист бар. Ләкин шулардан бары тик өч кенә кеше партия тарихын өйрәнүгә тиешенчә игтибар бирәләр. Бу, ВКП(б) райкомының өченче секретаре иптәш Горшунев һәм инструкторлардан Дәүләтшин һәм Закиров иптәшләр. Болардан калган работниклар политик белемнәрен күтәрү буенча үзлекләреннән эшләүгә җидди игтибар бирмиләр. Райкомның беренче секретаре иптәш Хәлиуллинне дә шундыйлар рәтенә кертергә мөмкин. Дөрес, ул китап өстендә эшлим ди, ләкин аның китап өстендә кайчан эшләгәнлеген әйтүе кыен. Без, райком работниклары, райкомның беренче секретарен һәр вакыт кабинетында күрәбез. Ул иртәннән башлап төнгә кадәр вактын шунда үткәрә. Кайчан гына карасаң да ул кабинетта ниндидер кәгазьләр актарып утыра, яки кемнедер телефонга чакыра, яки үзе телефон шылтыравына җавап бирә. Кабинетта уку белән шөгыльләнергә аңа бер дә вакыт тими торгандыр.

Райкомның икенче секретаре иптәш Мөхәммәтҗанов күбрәк игтибарны укуга бирә. Аны бик еш кулына журнал, брошюра тоткан хәлдә күрергә мөмкин. Ләкин аның бу эше җиңел характерда. Тирәнтен өйрәнү түгел. Мондый эш тиешле нәтиҗәне бирми. Укый башлады исә аны һәр төрле сөйләшүләр өчен бүләләр. Мондый укудан нинди нәтиҗә булсын.

Болар барсы да җитәкче работникларның үз вакытларын, уку өчен дә вакыт калдырырлык итеп бүлә белергә өйрәнмәүләрен күрсәтә. Алар әле үз вакытларының хуҗалары булырга өйрәнмәгәннәр. Райком секретарьларының начар үрнәгенә ияреп кайбер активистлар да ВКП(б) тарихын өйрәнүдә үзләренең артта баруларын дәвам иттерәләр. Алар эшләре күп булу белән һәм башка төрле объектив сәбәпләр белән аңлату юлына басалар. Без пропаганда мәсьәләләрен тикшерү өчен булган актив җыелышын зур кыенлыклар белән җыдык. 30—40 кешедән торган актив озак вакытлар җыелмады. Соңыннан берничә төрле башка мәсьәләләр тикшерәсе булгач кына җыелдылар.

Бу фактлар агитация һәм пропаганда эшен яхшыртуны активтан башларга кирәк икәнлекне күрсәтәләр. Әгәр дә без җитәкче работникларны ВКП(б) тарихын тирәнтен өйрәнүгә тарта алсак, башка работниклар да алар артыннан барырлар. Мин ВКП(б) Өлкә Комитетыннан үз эшләрендә эшләү буенча йомшак шөгелләнүче райком секретарьларының һәр вакыт исләренә төшереп торуын сорар идем.

Лекцияләр турында берничә сүз әйтергә кирәк. Безнең район тимер юлдан ерак тормый. Шулай да без квалификацияле лекторларны бик сирәк күрәбез. Бер ел эчендә алар бездә бары 4 тапкыр булдылар. Ә яхшы лекцияләргә сорау зур.

Район активының һәр айда кимендә бер лекция тыңлавын булдыра торган тәртип урнаштырырга кирәк. Бу лекцияләрне бер үк вакытта зур колхозларда да укырга кирәк. Обкомда лекторлар җитми, диләр. Бу—лекторларны күбрәк хәзерләргә кирәк дигән сүз.

Пропаганда эшендәге кимчелекләрне бетерергә

ИПТӘШ АНТОНОВ РЕЧЕННӘН

(Биләр районы)

Безнең районда бик күп иптәшләр „ВКП(б) тарихының кыскача курсы"н өйрәнү өстендә уңышлы гына эшлиләр. Олы тигәнә авылындагы тулы булмаган урта мәктәп укытучысы иптәш Гыймранов ВКП(б) тарихын өйрәнгәндә марксизм—ленинизм классиклары әсәрләреннән дә файдалана. Ул, Ленин әсәрләреннән: „Бер адым алга, ике адым артка", „нәрсә ул „халык дуслары" һәм алар социал демократларга каршы ничек сугышалар" дигән китапларны укыды. Иптәш Гыймранов агитколлектив җитәкчесе булып эшли, иптәшләргә бик күп ярдәм күрсәтә һәм коммунистлар арасында афторитеты да зур.

Районның алдынгы укытучысы, СССР хөкүмәте тарафыннан „Хезмәттәге батырлык өчен" медале белән бүләкләнгән иптәш Бочкарев та (ВКП(б) кандидаты), партия тарихын өйрәнү өстендә яхшы эшли. Ул хәзер „кыскача курс" ның 7 нче бүлеген өйрәнә.

Ләкин, эшнең бу өлкәсендә зур гына җитешсезлекләр дә бар әле. Райком җитәкчеләре үзләренең теоретик белемнәрен арттыру өстендә җитәрлек эшләмиләр. Беренче секретарь иптәш Федоров „Кыскача курс" ның бары беренче бүлеген генә өйрәнгән. Икенче секретарь иптәш Романов та һәм өченче секретарь иптәш Вафин да партия тарихын тирәнтен өйрәнмиләр. Үзенең политик белемен күтәрү өстендә кемнең ничек эшләве белән секретарьлар кызыксынмыйлар. Иптәш Вафинга „ВКП(б) тарихының кайбер мәсьәләләре буенча консультация алу өчен, мин сезгә коммунистлар җибәрәм" дисәң:

— Әгәр сез авыл хуҗалыгы мәсьәләләре буенча—кар тотуны ничек уздыру һәм башкалар турында консультация алырга килсәгез иде, мин сезгә консультация биргән булыр идем, ә партия тарихы мәсьәләләре буенча консультация бирә алмыйм, дип җавап бирә.

Район советы председателе иптәш Тележников аерым рәвештә өченче бүлекне генә өйрәнгән. Монсы да очраклы гына килеп чыккан, чөнки башлангыч партоешма шушы бүлек буенча теоретик беседа уздыруны билгеләгән булган.

Район партактивы арасында ВКП(б) тарихын начар өйрәнүче башка иптәшләр дә юк түгел. Шундый начар өйрәнүчеләр исәбенә, мәсәлән, хәзерләүләр комитеты уполномоченные иптәш Халиуллинны кертергә мөмкин. Без, парткабинет мөдире иптәш Ильдеткин белән иптәш Халиуллинне чакрып, ВКП(б) тарихын ничек өйрәнүе турында сөйләшергә булдык. Ә ул, „Әлегә бер ничек тә өйрәнмим" дип җавап бирде.

МТС директорлары Сократов һәм Кадыйров иптәшләр дә партия тарихын ныклап өйрәнмиләр. Алар икесе дә, тракторларга ремонт ясауны тәгәлләгәннән соң, партия тарихын өйрәнергә керешәбез, диләр.

Бу фактлар барсы да, безнең районда партия пропагандасының куелышы бүгенге сорауларга җавап бирерлек итеп оештырылмаганлыгы турында сөйлиләр. Безнең бурыч—пропаганда эшендә моңа кадәр кабатланып килгән кимчелекләрне бик тизлек белән бетерүдән, партия пропагандасы турында ВКП(б) Үзәк Комитеты карарын тулы үтәү өчен көрәшүдән гибарәт.

Матбугат пропагандасына зур әһәмият бирергә

ИПТӘШ СИРАЖИЕВ РЕЧЕННӘН

(Калинин районы)

Безнең районда партия оешмасы партия пропагандасын үзгәртеп коруда шактый эш башкарды. Районыбызда 700 гә якын кеше „ВКП(б) тарихының кыскача курсы"н үзлекләреннән өйрәнә. Аларның күпчелеге партия тарихын беренче чыганаклардан файдаланып өйрәнә.

Большевизмны үзләштерүдә партиянең җитәкче активы үрнәк күрсәтә. Мәсәлән, ВКП(б) райкомы секретаре иптәш Валиуллин „Кыскача курс" ның бөтен бүлекләрен конспект төзеп өйрәнеп бетерде. Актив арасында партия тарихын өйрәнүдә озак вакытлар бер урында торучы, хәтта үзләренең политик белем дәрәҗәләрен күтәрү белән шөгыльләнмәүчеләр дә юк түгел. Менә район башкарма комитеты председателе иптәш Ахметҗанов. Ул „Кыскача курс" ның 1—2 бүлекләрен инде ике айдан бирле өйрәнә. Район прокуроры, Киров исемендәге совхоз директоры һәм райпотребсоюз председателе үзләренең политик белем дәрәҗәләрен күтәрү буенча бөтенләй шөгыльләнмәделәр. Бары тик тикшергәннән соң гына һәм Өлкә Комитетның махсус карарыннан соң гына укый башладылар, ләкин ул да әле җитәрлек түгел.

„Правда" колхозы янындагы партоешма секретаре Мәҗитев, шул ук колхозның правление председателе Хәйруллин иптәшләр үзләренең политик белем дәрәҗәләрен күтәрү буенча җидди шөгыльләнәләр. „Алар ВКП(б) тарихының кыскача курсы" ның барлык бүлекләрен өйрәнделәр. Иптәш Мәҗитев юлбашчыларыбыз Ленин һәм Сталин иптәшләрнең таглиматларын өйрәнә. Иптәш Хәйруллин районыбызда иң яхшы агитаторларның берсе булып әверелде. Иптәш Мәҗитев җитәкчелек итә торган башлангыч оешма партиянең XVIII нче съездыннан соң 7 членга һәм 12 кандидатка үсте. Оешма колхозда социалистик ярышны җәелдерү буенча яхшы эшли, колхоз хәзер алдынгылар сафына басты.

Менә икенче төрле мисаль. Киров исемендәге совхоз директоры иптәш Латыйпов әле икенче бүлекне генә өйрәнә. Бу совхозның партия оешмасы секретаре һәм башка коммунистлары да партия тарихын әнә шулай акырын өйрәнәләр. Монда партия тарихын түбәнге звено буенча өйрәнү түгәрәге оештырылган. Ләкин ул начар эшли, тыңлаучылар аңа хәзерләнмичә киләләр. Коммунистларның, интеллигенциянең большевизмны ничек өйрәнүләрен партия оешмасы һәм аның җитәкчесе тикшерми, аларга ярдәм итми.

Матбугат пропагандасы турында берничә сүз. Соңгы көннәрдә өлкә газеталары һәм журналлары битләрендә консультация материаллары сирәк чыга башлады. Партия тарихын өйрәнүчеләргә бу материаллар бик кирәк. ВКП(б) Өлкә Комитеты, аерым алганда, аның пропаганда һәм агитация бүлеге киләчәктә моңа җидди әһәмият бирергә тиеш.

Пропаганда һәм агитация работникларының өлкә киңәшмәсендә. РӘСЕМДӘ: киңәшмәдә катнашучылардан бер группа. Сулдан—Ф. Е. Егоров, Т. В. Уразлин, С. Ш. Шакиров һәм Ш. Ш. Мөхитдинов иптәшләр. В. Лаврентьев фотосы.

Лекцияләрнең сыйфатын тагын да яхшыртыйк

ВКП(б) ӨЛКӘ КОМИТЕТЫ ЛЕКТОРЫ ИПТӘШ СЕМЕНОВ РЕЧЕННӘН

Безгә марксизм-ленинизм нигезләрен өйрәнү өчен бөтен мөмкинлекләр тудырылды: парткабинетлар бар, лекция һәм консультацияләр оештырыла, пропагандистлар армиясе зур булып үсте. Ләкин, без бөтен мөмкинлекләрдән тулысынча файдаланабыз дип әйтә алмыйбыз әле.

Мисальгә Балтач районын алырга мөмкин. Районның бай китепханәсе бар. Анда классикларның күп кенә әсәрләре, энциклопедияләр, борынгы һәм урта гасыр тарихы китаплары саклана. Парткабинеттан башка тагын лекцияләр өчен махсус зал оештырылган. Ләкин бу мөмкинлекләр кирәгенчә файдаланылмыйлар.

Аерым коммунистлар „эш күп", „вакыт юк" дигән сылтаулар табып, үзләренең политик дәрәҗәләрен күтәрү өстендә эшләмиләр. Красный Бор районында үткән җәй пропаганда эше онытылган иде. ВКП(б) Өлкә Комитетының күрсәтүе буенча райком бу мәсьәлә белән ныклап шөгыльләнә башлагач, эш торышы шактый яхшырды. Димәк, пропаганда эшенә җитәкчелек итәргә, эшне үз агымына куймаска кирәк.

Лекцияләр турында берничә сүз. Һәр райкомның пропаганда һәм агитация бүлеге лекцияләрнең сыйфаты өчен көрәшергә тиеш. Ләкин кайбер райкомнар лекцияләрнең төзелешенә, эчтәлегенә җидди игтибар итәсе урында, лекция „яхшы" һәм „канәгатьләнерлек" дип, аңа бик җиңел караганлыкларын күрсәтәләр. Шундый факт Ворошилов районы практикасында бар. Мәсьәләгә болай өстән генә карагач, яхшы лекцияне начарыннан аерып булмый. Ә кайбер урыннарда лекторны тәнкыйть итүдән дә качарга тырышалар.

Бу һәм шуңа ошашлы башка фактлар теорияне өйрәнү эшенә җидди игтибар биреп җиткермәүнең нәтиҗәсе булып торалар. Безгә большевизмны өйрәнү эшендә бөек Ленинннән һәм Сталиннан үрнәк ала белергә кирәк.

КИҢӘШМӘ ЗАЛЫННАН

5 нче гыйнварда пропаганда һәм агитация работникларының өлкә киңәшмәсенең иртәнге утырышында иптәш Матвеев доклады буенча фикер алышулар дәвам итте.

— Заинский районында,—ди иптәш Бигашов (райкомның пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире),—партиябезнең героик көрәш тарихын 500 дән артык кеше үзлекләреннән өйрәнәләр. Аларның 60 проценты партиясезләр. Үзләренең идея-политик дәрәҗәләрен күтәрү өстендә тырышлык күрсәтүче күп кенә иптәшләр җитәкче эшләргә күтәрелүгә ирештеләр.

Шулай да әле районның җитәкче работникларыннан күп кенә иптәшләр марксизм-ленинизм теориясен өйрәнүгә ныклап керешкәннәре юк. Ә райком секретарьлары пропаганда эшенең барышы белән көндәлек рәвештә кызыксынмыйлар һәм кирәгенчә җитәкчелек итмиләр.

Чистай райкомыннан сөйләүче иптәш Калмыйков та, район активыннан күп кенә иптәшләрнең ВКП(б) тарихын өйрәнергә вакыт „тапмауларын" күрсәткән фактларны китерә. Районның партактивистларыннан иптәш Бегайкин турында ул болай ди:

— Кайчан гына барсаң да аның эше күп, партия тарихын укырга вакты „юк". Үткән кышны „Халык переписе, бушап булмый" диде. Җәй көне сорашкач: „Хәзер эсседә нинди уку ул" ди. Алай да булмагач октябрь аенда сораштык. „Мин сайлау комиссиясендә эшлим, III нче бүлектә тукталдым" ди. Ә инде хәзер сорашкач: „Вакыт юк, терлекчелек переписе" ди. Ул менә шундый „сәбәпләр" табып кына тора. Бездә әле күп работниклар вакытны планлаштырып эш итә белмиләр.

Иптәш Майоров (Куйбышев районы) ВКП(б) тарихын үзлекләреннән өйрәнү эшен оештыру мәсьәләсенә районда дифферинциаль рәвештә якын килә белмәү фактлары булуын күрсәтә. Түбәнге эшләрдәге кадрларга, партия тарихын үзлекләреннән өйрәнү өчен әле белемнәре җитәрлек булмаган иптәшләргә аеруча игтибар бирергә кирәклеген әйтә.

Чүпрәле районыннан иптәш Галимов районда пропаганда эшенең хәзергә кадәр ныклы юлга куелып җитмәгәнлеге турында сөйләде. Районда 45 коммунист ВКП(б) тарихын өйрәнү эшенә һаман да керешмәгән. Райком да бу мәсьәләгә җидди игтибар бирми.

Беренче мәсьәлә буенча фикер, алышуларда шулай ук, Федоров, Адамов, Антонова, Жарков, Лебедева иптәшләр катнаштылар.

Фикер алышулардан соң докладчы иптәш Матвеев йомгаклау рече белән чыкты.

Икенче мәсьәлә буенча—халык арасында агитация-масса эшенең бурычлары турында ВКП(б) Өлкә Комитеты секретаре иптәш Долотказин доклады тыңланды.

Кичке утырышта доклад буенча сөйләүләр булды һәм киңәшмә үзенең эшен тәмам итте.

Матбугат күзәтү

Партия тормышын тулы һәм системалы яктыртырга

Партия тормышы мәсьәләләре һәрбер газета өчен үзәк мәсьәлә булып тора. Социалистик төзелешне оештыручы һәм рухландыручы большевиклар партиясенең күп төрле эш тармакларын тулы һәм системалы рәвештә яктырту—һәрбер газетаның төп бурычы.

„Мехчы" газетасы (Казмехкомбинат партоешмасы органы) бу җаваплы бурычны ничек үти соң?

Газета, 17 нче сентябрьдә, партия тормышы темасына—„ВКП(б) Өлкә Комитетының VII нче пленумы карарларын большевикларча үтәүне тәэмин итик" дигән исемдә баш мәкалә урнаштырды. Мәкаләдә партоешма алдынгы кешеләрдән күп кенә иптәшләрне партиягә кабул иткәнлеге турында әйтелә һәм бу эштә, бигрәк тә кандидатлар белән эшләү буенча булган җитешсезлекләр күрсәтелә.

Пленум карарларын тормышка ашыруга комбинатның киң массасын туплаучы баш мәкалә бирүе белән газета бик яхшы эшләгән. Ләкин редакция бу яхшы башлангычны дәвам иттерми, партия төзелеше мәсьәләләрен бөтенләй оныта. 3 айга якын вакыт үткәннән соң, редактор урынбасары иптәш Ш. Гамберов, онытылганда бер искә төшерү булсын дип, күрәсең, газетаның 3 нче декабрь номерында, „ВКП (б) сафлары үсә" дигән кыска гына бер хәбәр урнаштыра.

Дөрес, газетада агитация һәм пропаганда темасына язылган мәкаләләр һәм хәбәрләр бар. Ләкин, партия тормышы мәсьәләләре моның белән генә чикләнми. Партиянең пропаганда һәм агитация эшеннән башка, бик күп төрле оештыру һәм эчке мәсьәләләре бар. Партия җыелышлары, партдисциплина, карарларның үтәлешен тикшерү, партиягә яңа кабул ителгәннәр белән эшләүне оештыру, партия поручениеләре бирү һәм аларны үтәүдә ярдәм күрсәтү, партиясез актив белән эшләү мәсьәләләре турында газетада бер материал да күренми. Һәм шулай ук, предприятие администрациясенең эшенә партоешманың контрольлек итүе, кадрлар сайлап алу, аларны урнаштыру һәм тәрбияләү эше, стахановчылык хәрәкәтен оештыруда коммунистларның авангардлык роле, комсомол, профсоюз һәм ирекле җәмагат оешмаларына партия җитәкчелеге, партия хуҗалыгы, ВКП (б) уставы буенча партия оешмаларына йөкләнгән башка күп кенә эшләр турында газета конкрет бер нәрсә дә язмый. Ә бит болар барсы да партия төзелешенең актуаль мәсьәләләре. Цех партбюро һәм партгруппаларының җитәкчеләре, оешмадагы барлык коммунистлар газетадан әнә шулар турында конкрет һәм системалы рәвештә яктыртуны көтәләр. Коммунистлардан җитәкчелек эшенә яңа күтәрелгән, партиянең оештыру һәм эчке эшләрендә тәҗрибәләре җитәрлек булмаган иптәшләр аз түгел. Алар газетадан үзләренең эшенә ярдәм итүне, тәҗрибәләрне уртаклашуны һәм кимчелекләрне күрсәтүне таләп итәләр.

„Мехчы" газетасы оешмадагы коммунистларның бу таләпләрен үтәүдән ерак тора, ныклы инициативалы эш алып бармый. Редакция работниклары башлангыч партоешманың эшендәге үзгәрешләр белән көндәлек рәвештә танышып тормыйлар, партия төзелеше буенча принципиаль характердагы мәсьәләләрне үз инициативалары белән күтәреп чыкмыйлар. Алар партия җыелышында тикшерелгән яки партбюро тарафыннан ачылган фактларны теркәп үтү белән генә чикләнәләр. Моның шулай икәнлеге партия тормышы темасына урнаштырылган материалларда ачык күренеп тора. Мәсәлән, 17 нче сентябрь номерындагы баш мәкаләдә: „Партиянең Мехкомбинат оешмасы бюросы кандидатлык стажы срогы үткән иптәшләр белән 13 нче сентябрьдә беседа үткәрде" диелә һәм шул беседа вактында ачылган фактлар мисаль итеп китерелә. Ә редакция работниклары яңа фактларны таба белергә, партоешмага яңа нәрсә белән ярдәм итәргә тиешләр иде.

Партия тормышы мәсьәләләрен бу газетаның кирәгенчә яктыртмавының төп сәбәбе—редакция (редактор иптәш Масаутов) партоешманың көндәлек эшен тирәнтен белмәүдә, бу өлкәдә планлы эш оештырмауда һәм партия активын газета тирәсенә туплау эше белән чын-чыннан шөгыльләнмәүдә. Хәбәрчеләр белән июль аеннан бирле бер киңәшмә дә үткәрелмәү факты да моңа бик ачык мисаль булып тора. Партия активыннан газетага язышучылар берничә генә кеше исәпләнә. Алар да сирәк язалар. Ә комбинатта 500 гә якын коммунист һәм шул ук санда комсомолец эшли. Аларны редакция тирәсенә оештырырга һәм алар белән көндәлек элемтә урнаштыра белергә генә кирәк.

„Мехчы"—Казан шәһәрендә чыга торган күп тиражлы газеталарның иң зурларыннан берсе. Бу газетада партия тормышы мәсьәләләрен, ВКП(б) Үзәк Комитеты таләп иткәнчә, тулы һәм системалы яктырту өчен бөтен мөмкинлекләр бар. Бары тик эш җитәкчеләргә, аларның бу мәсьәләне игтибар үзәгенә куя белүләренә бәйләнгән.

СОЦИАЛИСТИК ТЕРЛЕКЧЕЛЕКНЕҢ ЯҢА КҮТӘРЕЛЕШЕ ӨЧЕН

„Активист" колхозы фермасы сыер сауучы стахановчылары, Олы Кошман авыл советы депутатлары Сабирә Камалиева һәм Зәда Гыйматова иптәшләр. Х. Яруллин фотосы.

Безнең уңышларыбыз —социалистик ярыш нәтиҗәсе

„Активист" колхозының товарлыклы - сөтчелек фермасы үзенең уңышлары белән бик хаклы рәвештә мактана ала. Чыннан да, моннан бары 3 кенә ел элек әле елына 700 литр, күп дигәндә 1.000 литр сөт биргән гади сыерлардан соңгы ике елда 2.000, 3.000 хәтта 6.000 литрдан артык сөт савып алуга ирешү—кечкенә уңыш түгел ул.

Безнең уңышларга ирешүебездә, фермада зоотехника һәм ветеринария кагыйдәләрен тормышка ашыру белән бер рәттән, үзара ярышып эшләү көчле этәргеч булды. Безнең уңышларыбыз,—алар социалистик ярыш нәтиҗәсе булып торалар.

Фермабыз шул ук Кайбыч районының Мөрәле авылы, Карл Маркс исемендәге колхозның товарлыклы - сөтчелек фермасы белән ярыша. Без, сыер сауучылар да һәм фермада эшләүче башка колхозчылар да, бөтенебез дә социалистик ярыш белән чолганып алынган.

„Колхозларда җәмагать терлекчелеген үстерү чаралары турында" ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм СССР Халык Комиссарлары Советының карары бездә эшкә булган дәртне, киләчәктә тагын да зуррак уңышларга ирешү теләген чиксез көчәйтте.

Үзара ярышып эшләү безгә терлекчелек өчен яңа кадрлар җитештерүгә, аларның квалификацияләрен күтәрүгә бик нык ярдәм итә. Чөнки без ярыш договорларында эштә бер-беребезгә үзара булышуны төп шартларның берсе итеп куябыз. Кем кемгә булышкан һәм бу булышлыкның нәтиҗәсе нинди—хисапка алып барабыз. Мисаль өчен, яш кадрларыбыздан Шәйхелбәнат иптәш Гатауллинаны күрсәтергә мөмкин. Сыер сауучы булып ул бары 3 кенә ай эшли әле. Башта сыер сауу техникасын иптәш Гатауллина бөтенләй дип әйтерлек белми иде. Без аңар социалистик ярыш договорлары нигезендә барыбыз да бергәләп булыштык һәм ул хәзер үз эшен шактый яхшы итеп үзләштереп килә. Үзенә беркетелгән сыерларны яхшы тәрбия итә.

Без 1940 нчы елда ферма буенча һәрбер сыердан уртача кимендә 3.000 литр сөт савып алуга ирешүне йөкләмә итеп алып, Кайбыч районындагы барлык терлек фермаларында эшләүчеләрне социалистик ярышка чакырдык. Без үз арабызда социалистик ярышны тагын да киңрәк җәелдереп, бу йөкләмәне үтәрбез генә түгел, хәтта арттырып та үтәрбез. Хәзерге көндә безнең белән ярышучы, ләкин безнең фермадан барлык күрсәткечләр буенча, бигрәк тә яш терлекләрне саклау буенча бик артта калучы Мөрәле авылы, Карл Маркс исемендәге колхозның товарлыклы - сөтчелек фермасының да ярышта уңышларга ирешүе өчен тырышырбыз. Терлек азыкларыннан бик дөрес итеп һәм экономия белән файдаланып, һәр ике фермада да терлекләрнең үрнәк рәвештә кышлауларын, күп сөт бирүләрен тәэмин итәрбез.

Җирле Советларга сайлаулар вактында мин Кошман авыл советына депутат булып сайландым. Халыкның бу ышанычын тулысынча аклармын. 1940 нчы елда үз фермабызның гына түгел, гомумән социалистик терлекчелекне алга җибәрү өчен бөтен көчемне биреп эшләрмен.

С. Камалиева.

Кайбыч районы, Кошман авылы „Активист" колхозының товарлыклы - сөтчелек фермасы сыер сауучысы.

БЕЗ УҢЫШЛАРГА НИЧЕК ИРЕШТЕК

Моннан бары 3 кенә ел элек безнең фермабызда сыерларның сөт бирүләре чиктән тыш түбән иде.

1934 нче елда мин фермага мөдир итеп билгеләнгәннән соң, фермадагы иптәшләр белән киңәштек һәм фермабызны алга җибәрү өчен ныклы чаралар билгеләдек.

Без эшне ферма өчен холмогор нәселле үрчеткеч сатып алудан башлап җибәрдек. Сыерларның бер өлешен группалап тәрбиягә, ә бер өлешен индивидуаль тәрбиягә куйдык. Терлек азыкларын экономия белән тотуга аеруча әһәмият бирдек, азыкны норма һәм рацион буенча бирә башладык, тупас азыкларны парлап ашатуга күчтек, хезмәтне яңача оештырып, иясезлекне, хезмәт көннәре язуда тигезләүчелекне бетердек.

Бу чараларны тормышка ашыру безгә искиткеч зур нәтиҗәләр бирде. 1931 нче елда фермабызда бары 24 баш терлек бар иде, хәзер аларның саны 129 башка җитте. 1935 нче елда көненә бары 1,5 литр, елына бары 1.300 литр сөт биргән „Маруся" исемле сыерыбыз 1936 нчы елда 2.373 литр, 1937 нче елда 3.477 литр, 1938 нче елда 5.665 литр, 1939 нчы елның 1 нче декабренә 6.110 литр сөт бирде. 1937 нче елда бары 884 литр сөт биргән 18 нче номерлы сыерыбыз 1938 нче елда 1465 литр, ә 1939 нчы елны 1.600 литр сөт бирде. 22 нче номерлы сыерыбыз 1937 нче елда бары 1.100 литр сөт биргән булса, 1938 нче елда 2.253 литр сөт бирде.

Ферманың акчалата доходы бигрәк тә тиз үсте. 1938 нче елда ферманың акчалата доходы колхозның акчалата доходының 37,8 процентын тәшкил иткән булса, 1939 нчы елда 60 процентын тәшкил итә.

Хезмәтне дөрес оештыру бу уңышларга ирешүдә хәл иткеч төп чара булды. ВКП(б) ның XVIII нче съездында сөйләгән речендә иптәш Андреев:„... Колхозларда хезмәт звенолар яки аерым колхозчылар төсендә никадәр күбрәк индивидуаллаштырылган булса, аларның хезмәтләре материаль яктан никадәр күбрәк кызыксындырылган булса, ул иген уңышында да, шулай ук терлекчелектә дә шул кадәр нәтиҗәлерәк булачак" дип әйтте.

Иптәш Андреевның бу күрсәтмәсен без үз фермабызда тормышка ашыруга аеруча нык игтибар бирдек.

Безнең фермада хезмәт ничек оештырылган соң? Бездә һәрбер сыер сауучыга 10 сыер беркетелгән. Сыер сауучыларга хезмәт көннәре аларга беркетелгән сыерлардан алына торган продукциянең (сөтнең) күләменә карап (100 литр сөткә 1,8 хезмәт көне) язылa. Һәрбер каплатылган сыер өчен 1,0 хезмәт көне, һәрбер беренче бозау анасын бозаулаткан һәм аның бозавын 15 көн тәрбия иткән өчен 17 хезмәт көне, һәрбер карт сыерны бозаулаткан һәм аның бозавын 15 көн тәрбияләгән өчен 15 хезмәт көне язылa.

Сыерлардан продукцияне күп алу белән бездә шулай ук скотник-көтүче дә турыдан-туры кызыксындырылган.

Хезмәт көннәре аңар да продукциянең чыгышына карап язылa.

Фермада эш иртә белән сәгат 4 тә башлана. Сыер сауучылар сыерларның өсләрен һәм асларын көнгә ике тапкыр (иртә һәм кич) чистарталар. Әгәр һава начар булмаса, иртә белән (сәгат 11 ләргә кадәр) 2—3 сәгаткә сыерларны ачык һавага чыгарабыз. Көнлек азык һәрбер сыерга карата өчкә, дүрткә, бишкә бүленеп бирелә. Кайбер сыерлар 3 тапкыр, кайберләре 4 әр һәм 5 әр тапкыр савылалар.

Без 1940 нчы елда ферма буенча һәрбер сыердан кимендә 3.000 литр сөт савып алуга ирешүне йөкләмә итеп алдык. Кайбыч районының барлык ферма работникларын үзебез белән тиңләшергә чакырдык. Без үзебезнең йөкләмәбезне, һич шиксез, тулысынча үтәрбез. Моның өчен без барлык мөмкинлекләрдән тулысынча файдаланабыз.

Х. Шаһидуллин.

Кайбыч районы, Кошман авылы „Активист" колхозының товарлыклы - сөтчелек фермасы мөдире.

Хәбибулла иптәш Шаһидуллин. Х. Яруллин фотосы.

СЫЕРЛАРНЫ ТУЙДЫРУ БУЕНЧА МИНЕМ ТӘҖРИБӘМ

Мин 1931 нче елдан бирле фермада эшлим. Башта 3 ел рәттән бозаулар караучы булып эшләдем. Шул 3 ел эчендә барлыгы 116 бозау карап үстердем. 1934 нче елдан сыер сауучы булып эшлим. 1939 нчы елны Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә катнаштым һәм быел да катнашачакмын. Чөнки мин үземә беркетелгән сыерлардан 1939 нчы елның 1 нче декабренә үк уртача 2.700 литр сөт савып алдым инде. Мин тәрбияли торган сыерларның „Маруся" исемлесе 1939 нчы елның шул ук 1 нче декабренә 6.110 литр сөт бирде. „Маруся" гади нәселле сыер. Аңарда тик берникадәр симменталь нәсел билгеләре бар.

Инде хәзер үземнең эшем турында берничә сүз. Мин сыерлардан, аеруча „Маруся" дан шактый күп сөт алуга ничек ирештем соң? Барыннан да элек, шуны әйтергә кирәк: һәрбер сыерга карата тәрбия мәсьәләсендә аерым эш итү минем уңышларга ирешүемдә хәл иткеч чара булды. Азыкны сыерларга дөрес төзелгән рацион буенча бирәм. Ләкин без, ферма эшчеләре, рационны дөрес төзү генә әле уңышны хәл итмәвен яхшы беләбез. Эш, рацион буенча билгеләнгән азыкның терлек тарафыннан зур теләк белән, аппетит белән ашалуында.

Мин, һәм гомумән безнең ферма работниклары сыерларны көнгә ике тапкыр гына сауууны күптән ташладык инде. Күпчелек сыерларны 3 тапкыр, ә кайбер сыерларны 4—5 тапкыр савабыз. Сыерны никадәр күп саусак, аңар рацион буенча билгеләнгән көнлек азыкны да шулай сауган саен азлап бирәбез. Азыкны әнә шулай порцияләп бирү аның сыер тарафыннан тулысынча үзләштерелүенә, ә бу исә азыкның экономия белән тотылуына һәм ниһаят, сөтнең күп чыгуына илтә.

Җиленгә сөт күп җыелу белән генә дә әле эш бетми. Аны савып ала белү дә кирәк. Шуңар күрә безнең фермада сыер сауу техникасына җидди игтибар бирелә. Һәр сауганда җиленгә 3 тапкыр(савар алдыннан, сауу тәмам булу алдыннан һәм сауу тәмам булганнан соң) массаж ясыйбыз. Элек алдынгы имчәкләрен, аннан соң арттагы имчәкләрен савабыз.

Күп кенә фермаларда бик әһәмиятле бер нәрсәне истән чыгаралар. Ул—фермада тынлык саклау. Бездә бу нәрсә мәҗбүри бер шарт итеп куелган. Савым сыерга карата моның әһәмияте гаять зур. Мисаль өчен мин шул ук „Маруся" не алам. Абзарда тынлык бозылды исә, шул көнне „Маруся" сөт бирүне аз дигәндә 4—5 литрга кимeтә.

Терлек азыгын экономия белән тотуның һәр яктан әһәмиятле булуы бәхәссез. Быел моның әһәмияте аеруча зур. Бу өлкәдә дә безнең фермабызның уңышлы тәҗрибәсе бар. Үткән елны без ферма мөдире иптәш Шаһидуллинның инициативасы белән берлектә башак болгатып бирү буенча бер тәҗрибә үткәрдек. Саламны чылату өчен иң элек ачкылт махсус су хәзерләдек. Моның өчен 8 килограмм бәрәңгене өшеттек һәм издек. Шуннан соң аңар 6 килограмм өшегән чөгендер куштык. Шуларны бер кисмәккә тутырып 16 чиләк су салдык һәм аз гына чүпрә җибәрдек. Бер тәүлек эчендә бу суыбыз ачкылт тәмле суга әйләнде. Шуннан соң ваклап тураган арыш саламын шул суга чылатып, биеклеге һәм киңлеге бер метр, озынлыгы 3 метрлы яшчиккә 20 сантиметр калынлыгында түшәдек. Аның өстенә 10 сантиметр калынлыкта шундый ук саламны чылатмыйча түшәдек. Шулай итеп ящик тулганчы саламны тыгызлап тутырдык. Ящиккә барлыгы 2,5 центнер салам һәм әлеге 16 чиләк су кереп бетте. Һәрбер катлауга аз гына тоз сиптек. Саламны өстән ныклап бастырып куйдык. Бер тәүлек тулганда бу салам тәмам йомшарып житте. Шуннан соң аны аз гына он сибеп 70 баш терлеккә бүлеп бирдек.

Саламны шулай хәзерләп ашату безгә чама белән саламга 50 процент, аңа сибелә торган онга 40 процент экономия ясарга мөмкинлек бирүен белдек. Азыкны быел да шулай ашатабыз һәм башкаларга да шулай эшләргә киңәш бирәбез.

Фатыйма Гыйматова.

Кайбыч районы, Кошман авылының товарлыклы сөтчелек фермасының сыер сауучысы.

Фатыйма иптәш Гыйматова. Х. Яруллин фотосы.

„Активист" колхозы фермасының бозау караучы стахановчылары Фатыйма Тимергалиева һәм Нурсәйдә Хәйретдинова иптәшләр. Х. Яруллин фотосы.

Яш терлеккә нык игтибар бирик

Яш терлекне саклауга, аны яхшылап тәрбияләүгә без аеруча нык игтибар бирәбез. Мин „Активист" колхозы фермасында 3 елдан бирле инде бозау караучы булып эшлим. 1938 нче елны 56 бозау, 1939 нчы елны 33 бозау карап үстердем. Барлык бозауларны да сәламәт үстерүем өчен һәм һәрбер бозауның көн саен үсешен норма буенча 550 грамм урынына 650 граммга җиткерүем өчен 1939 нчы елны мин Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә экспонент булып катнаштым. Күргәзмәдә катнашу миңа бик күп тәҗрибә бирде. 1940 нчы елда да күргәзмәдә катнашуга хокук бирерлек күрсәткечләргә ирештем.

Безнең фермада бозау авыруы, бигрәк тә бозау үлү кебек кимчелек юк дәрәҗәсендә аз. Моның төп сере бозауларны дөрес тәрбия итүдә һәм аларга карата иясезлекне бетерүдә. Ә болай эшләргә һәр колхоз фермасында да мөмкинлекләр зур.

Безнең фермада бозау тугач та 15 көнгә кадәр сыер сауучы тәрбиясендә була, аннан соң бозау караучыга күчә. Бозау караучыга, әгәр дә ул карый торган бозауларның көрлеге яхшы булса, һәрбер бозау өчен аена 0,90 хезмәт көне, әгәр дә бозауларның көрлеге уртачадан түбән булса, һәрбер бозау өчен аена 0,70—0,80 хезмәт көне язылa.

Сөт белән туйдыру бозау тәрбияләүдә бигрәк тә җаваплы эш. Бозауга сөтне кирәгеннән артык та һәм шулай ук ким дә эчерергә ярамый. Бозауларга без угыз сөтен дә кертеп 170 литрдан 250 литрга кадәр саф сөт һәм аннан соң 250—300 литр сепаратор сөте эчерәбез. 15 көн үткәч тә сөткә аз гына солы оны кушабыз. Сөт эчерү чоры ике, ике ярым айга кадәр дәвам итә. Аннан соң акрынлап яхшы печән бирә башлыйбыз. Көнгә 200—300 грамм хисабыннан солы көрпәсе бирәбез. 3 ай чамасы үткәч, көрпәне 400 граммга җиткерәбез һәм 3 айдан соң инде акрынлап башак бирүгә күчәбез.

Кайбер фермаларда бер яш тулгач та бозаулар, аларга әлләни тәрбия кирәкми инде дип, я бөтенләй тәрбиячесез калдырылалар, яисә сыер сауучыларга өстәмә итеп беркетеләләр. Без мондый кимчелеккә һич тә юл куймыйбыз. Бездә бозау бер яш тулганнан соң яш терлек караучыга беркетелә.

Фермабызның бозау абзарлары якты, төзек һәм җылы. Яш бозаулар өчен аерым клеткалар бар. Клеткаларның идәннәрен көн саен кайнар су белән бик яхшылап юабыз һәм яхшылап киптерәбез, һаваны әледән-әле алыштырып торабыз.

Бозауларны без әнә шулай тәрбия итәбез.

Социалистик ярыш договоры буенча 1940 нчы елда без барлык бозауларны сәламәт үстерергә һәм аларның көнлек үсешләрен уртача 700 граммга җиткерергә тиешбез. Мин фермабызның бу йөкләмәсен үтәүдә актив катнашачакмын.

Ф. Тимергалиева.

Кайбыч районы, Кошман авылы, „Активист" колхозының бозау караучысы.

Сыерлардан сөт алуны арттыру тәҗрибәсе

Үткән кышны Юдино районының „Яңа Тормыш" колхозына Казан зооветеринария институтының зоотехника кафедрасының фәнни работниклары бригадасы килгән иде. Зоотехниканың иң гади чаралары комплексын куллану юлы белән сыерлардан сөт алуны шактый күтәрүгә ничек ирешү мөмкинлеген колхозчыларга күрсәтүне бригада үзенең бурычы итеп куйды.

Юдино районы—терлекчелек өлкәсендә нык артта калган район. Шуңа күрә дә зоотехника кафедрасы сотрудниклары сыерлардан сөт алуны арттыру буенча эшне бу колхозда башлап җибәрделәр. Шуның белән бергә колхозның Казанга якын булуы фәнни работникларга колхоз белән ныклы элемтә тотарга мөмкинлек бирде.

Бу колхоз фермасының 1938 нче елдагы күрсәткечләре югары түгел иде. Анда нәселсез, гади, үлчәүләре зур булмаган һәм һәрбер фураж сыерына бары 900 литрга кадәр генә сөт бирә торган 48 савым сыер бар иде. Сыерларны тәрбияләү һәм ашату начар куелган, аларның продукция бирүләре һәм буазлыклары исәпкә алынмый иде. Сыерларның барсына да бер үк төрле азык рационы бирелә, минераль азыклар бирелми иде. Тупас азыкларны эшкәртеп ашату кулланылмады. Бригада эшкә башлаганда һәрбер савым сыер көнгә уртача бары 2,88 литр гына сөт бирә иде.

Хезмәтне оештыру хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү белән кызыксынырлык итеп куелмаган иде. Ферма работниклары арасында социалистик ярыш кулланылмады. Сөт савып алуның айлык һәм көнлек планнары төзелмәгән иде. Эш планын үтәгән һәм продукция эшләп чыгарган өчен премиаль система кулланылмаган иде.

Бригада, ВКП(б) ның XVIII нче съезды исемендәге социалистик ярышка кушылып, 1938 нче елның 2 нче февралендә эшкә башлады. Сыерларның сөт бирүләрен фермага Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә катнашуга хокук бирерлек дәрәҗәгә кадәр күтәрү турында йөкләмәләр алынды.

Барыннан да элек, без аерым зоотехника чараларының әһәмиятен аңлата башладык. Азык планы төзедек. Продукция бирүенә карап, һәрбер сыерга күпме азык бирелергә тиешлеген исәпләп чыгардык. Буаз сыерларны бозаулауга хәзерләү өчен аларга азык нормалары билгеләдек. Һәрбер сыер сауучы үзе сава торган сыерлар группасына кирәкле көнлек азыкларның билгеле исәбен алды. Ул шушы исәп буенча ферма мөдиреннән терлек азыклары таләп итә ала иде.

Бу планнар колхозның терлекчелек работниклары киңәшмәсендә кабул ителделәр һәм шуннан соң колхоз правлениесе тарафыннан расландылар. Шул ук киңәшмәдә товарлыклы - сөтчелек фермасында эшләрнең яңа тәртибе кабул ителде. Сыерларны көнгә өч тапкыр сауууга күчү билгеләнде. Сыерларны кыш көне иртәдән кичкә кадәр ачык абзарда тоту урнына аларны билгеле сәгатьләрдә генә ачык һавада йөртү тәртибен керттек.

Парлагычтан файдаланып, тупас азыкларны эшкәртү эшен оештырдык. Минераль азык ашатуны керттек. Сауучылар сыерларны һәр көн чистарта, яхшырак сава һәм массаж куллана башладылар.

Барлык сауучылар, социалистик ярышка кушылып, фәнни работникларның тәкъдимнәрен күңел биреп үти башладылар. Һәрбер сауучыга һәр сыердан һәм үз группасындагы барлык сыерлардан сөт савып алу планы бирелде. Хезмәт өчен түләүне оештырудагы кимчелекләр бетерелде.

Эшнең бик яхшы нәтиҗәләре шактый тиз күренде. Әгәр дә һәр савым сыерның тәүлектә уртача күпме сөт бирүен 1938 нче елдагы белән чагыштырсак, 1939 нчы елның беренче 11 ае эчендә түбәндәге картинаны күрербез: 1938 нче елның февралендә 1,86 литр, июнендә—5,6, ноябрендә—1,4 литр алынган булса, 1939 нчы елның февралендә 4,51, июнендә 8,9, ноябрендә 3,1 литр сөт алынды.

1939 нчы елның 1 нче ноябренә сыерларның сөт бирүе һәр сыерга уртача 1.605 литрга җитте. Икенче төрле әйткәндә, 1938 нче ел эчендә алынганнан 700 литр артыграк сөт савып алынды.

1938 нче елның декабрендә бозаулаган 10 сыерның сөт бирүләрен күтәрү буенча үткәрелгән чаралар аеруча яхшы нәтиҗәләр бирде. Тәрбия эшен яхшырту аркасында, бу 10 сыер шуннан соңгы айларда үзләренең сөт бирүләрен нык кына арттырдылар. Мәсәлән, бу сыерлар 1938 нче елның декабрендә 751 литр сөт биргән булсалар, 1939 нчы елның гыйнварында 650, февралендә 1.116, мартында 1.408 литр бирделәр.

Сыерларны бозаулауга тиешле рәвештә хәзерләү дә яңа бозаулаган сыерларның сөт бирүләрен күтәрүгә яхшы йогынты ясады. Яңа бозаулаган һәрбер сыер уртача һәр тәүлеккә декабрь аенда 4,76, февральдә 7,1, мартта 11,3 литр сөт бирде.

Нәселсез, гади сыерлар арасыннан тәүлеккә 18 литрдан артыграк сөт бирә торган ике рекордистка сыер табылды (элек алар бары 10 литрга кадәр генә сөт биргәннәр).

Колхоз дәүләткә сөт тапшыру планын срогыннан элек һәм арттырып үтәде.

Товарлыклы - сөтчелек фермасында нәсел үрчетү эше дә юлга салынды. Чаптыру һәм сыерларны бозаулату планы төзелде. Нәселле терлекләр сатып алу хисабына товарлыклы сөтчелек фермасын киңәйтү күздә тотыла.

Товарлыклы сөтчелек фермасын азык базасы белән тәэмин итү өчен күп кенә чаралар үткәрелде. Терлекләрне кышлатуга кую алдыннан колхоз 200 тонна силос (100 тонна көнбагыш, 20 тонна кыяклы печән һ. б.) хәзерләде.

1939 нчы елның 1 нче декабренә товарлыклы - сөтчелек фермасы колхозга 61 мең 371 сум доход бирде.

„Яңа Тормыш" колхозында сыерларның сөт бирүләрен арттыру буенча үткәрелә торган эш нәтиҗәләре хәтта нәселсез, гади сыерларның да сөт бирүләрен нык кына күтәрергә мөмкин икәнлекне күрсәтте.

П. Сырнев.

Казан Зооветеринария институты профессоры.

Чит илләрдә

ЕВРОПА СУГЫШЫ

ПАРИЖ, 4 гыйнвар. (ТАСС). Гавас агентлыгы көнбатыш фронттагы сугыш хәрәкәтләре турында түбәндәге хәбәрне тапшыра: „Каты салкынга да карамастан, Германия һәм Франция позицияләре арасындагы буш районда патрульләрнең һәм разведка отрядларының гадәттәге операцияләре дәвам итә.

Франция һәм Германия авиацияләре разведка очышлары ясыйлар. Төньяк дингез өстендә Англия самолетлары һава сугышы вактында Германиянең бер самолетын бәреп төшерделәр. Англичаннар бер самолетларын югалттылар; бер самолет үзенең базасына кайтмады“.

Кичә кич Парижда игълан ителгән рәсми белдерүдә болай диелә: „Көн буена фронтның төрле участкыларында патрульләр һәм разведка отрядлары уңышлы хәрәкәт иттеләр. Иртә белән безнең истребительләребез дошманның ике самолетын бәреп төшерделәр“.

Иртәнге белдерүдә „төн буена бер нәрсә дә булмады“ дип хәбәр ителә.

ЛОНДОН, 4 гыйнвар. Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Швеция соңгы айда диңгездә булган сугыш нәтиҗәсендә барлыгы 17.524 тонна авырлыгындагы 11 пароходын югалткан.

Соңгы атна эчендә Франция властьлары нейтраль илләрнең 10 судносын тикшергәннәр һәм 27.000 тонна товарны тотып калганнар.

НЬЮ-ЙОРК, 4 гыйнвар. Ассошиэйтед пресс агентлыгының хәбәр итүенә караганда, англичаннар Американың „Эксекутив“ исемле пароходын тотканнар. Англичаннар бу пароходтагы 13 мең фут никель трубаны басып алганнар.

Американың 29 нчы декабрьдә англичаннар тотып алган „Экскалибур“ пароходы азат ителгән.

(ТАСС).

Англия капиталистлары һәм ак Финляндия

ЛОНДОН, 4 гыйнвар. (ТАСС). „Иоркшир обсервер“ газетасы йон промышленностына бәйле булган күп кенә Англия сәүдә-промышленность фермаларының Хельсинкидән 30 миль төньяктарак булган пункттан—Хювенкядән түземсезлек белән мәглүматлар көтүләре турында хәбәр урнаштыра. Бу тынычсызлануның сәбәбе Англиядәге Юнайтед Вуллен Миллс компани Лимитед концернының Хювенкядә йон фабрикалары булу белән аңлатыла. Бу фабрикалар—төньяк Европада иң эре предприятиеләрдән саналалар. Хювенкядәге йон фабрикасында 2 мең эшче һәм хезмәткәр бар. Газетаның язуына караганда, Англиянең күп кенә кешеләре үзләренең капиталларын шушы фабрикаларга һәм Хельсинкидәге концернга салганнар. Бу англичаннарның күбесе—элекке финнәр, хәзерге вакытта Англия гражданнары булып әверелгән кешеләр. Финляндиянең Лондондагы беренче илчесе Доннер күп еллар буена бу концернның башлыгы булып торды. Аның улы Патрик Доннер — Англия парламентының члены һәм Англиянең оборона координациясе буенча хәзерге министре лорд Чэтфильдның кияве.

Маннергейм бандаларының тыныч халыкны ерткычларча күчләүләре

СТОКГОЛЬМ, 4 гыйнвар. (ТАСС). Ак фин сугыш чукмарларының үз халыкларын җәзалаулары кебек коточкыч рәхимсезлекне тарихның әле күргәне юк иде. Кешеләрне туган җирләреннән көчләп куалар. Тылдагы авылларда хәрби жандармерия отрядлары кешеләрне җыеп, аларны туган урыннарыннан алып китәләр. Ак финнәр халыкның Финляндия халык армиясе ягына чыгуыннан куркалар. Финляндия халкы халык армиясенә теләктәшлек белдерә. Швециядә чыга торган „Дагенс нюхетер“ исемле буржуаз газетаның хәбәрчесе Финляндия халкының Совет частьләренә проводниклар бирүен яза. Хәрби жандармерия халык арасында массовый облавалар ясый. Барлык хәрби кешеләрнең пропусклары һәм документлары әледән-әле тикшерелеп тора, чөнки дезертирлык массовый күренеш булып әверелде.

Ак фин гаскәрләре чигенгәндә бөтен җирләрне яндыралар. „Дагенс нюхетер“ газетасының махсус хәбәрчесе болай дип яза: „Фин солдатларының йорттан-йортка күчеп аларны яндырып йөрүләре хәтта Норвегия чигеннән дә күренә. Бетон корылмалар һәм күперләр шартлатыла“.

Куылган фин халкы Норвегия территориясендә котылу урыны эзли. Хәбәрче болай дип яза: „Без салкынга һәм карга карамастан, караңгы кышкы төннәрдә Норвегия чиген кичү өчен юл эзләүче качаклар төркемен күрдек“.

ВАН ЦЗИН-ВЕЙ ГРУППАСЫНДА КАРШЫЛЫКЛАР

ШАНХАЙ, 4 гыйнвар. (ТАСС). „Цзунмэйжибао“ газетасының хәбәр итүенә караганда, Ван Цзинвей группасында каршылыклар дәвам итә. Газетаның сүзләренә караганда, күптән түгел генә Ван Цзин-вейнең шәхси сакчылык гаскәрләре капитаны—Чжан Сень һәм курчак хөкүмәт гаскәрләренең элекке командиры Ван Тяньму хыянәтчелектә гаепләнеп җәзалап үтерелгәннәр.

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

(ТАСС хәбәрләреннән)

КӨНЬЯК КЫТАЙДА

„Дамэйбао“ газетасының хәбәр итүенә караганда, 2 нче гыйнварда кытай партизаннары Фучжоудан көньяк-көнчыгышта, Фуцзян провинциясе яры янында Хэдань атавындагы япон частьләренә көтелмәгәндә атака ясаганнар һәм аны японнардан чистартканнар. Япон гаскәрләренең калдыклары атауны ташлап киткәннәр.

ҮЗӘК КЫТАЙДА

Хубэй провинциясенең көньяк өлешендә кытай гаскәрләре күп кенә пунктларны алып Тунчэндәге япон гаскәрләрен изоляцияләгәннәр.

Цзянси провинциясенең төньяк өлешендә кытай частьләре Наньчаннан төньяк-көнбатыштагы Фынсинь шәһәренә төньяктан бәреп кергәннәр. Монда алар японнарның 2 сугыш складын яндырганнар, берничә дистә винтовка, противогазлар һәм обмундирование кулга төшергәннәр.

ТӨНЬЯК КЫТАЙДА

Шаньси провинциясенең көньяк-көнчыгыш өлешендә кытай гаскәрләре Чжанцзыдан төньяк-көнчыгышкарак 30 километрга алга киткәннәр.

Хэнань провинциясенең төньяк өлешендә кытай частьләре яңа ел алдыннан Хуайцин шәһәрендә япон позицияләренә атака ясаганнар. Сугыш тәүлек буена дәвам иткән. Кытайлар шәһәргә бәреп кереп урамнарда японнар белән сугышканнар. Японнарның 500 ләп кешеләре үтерелгән һәм яраланган. Кытайлар японнарның берничә пулеметларын һәм мылтыкларын кулга төшергәннәр.

ИСПАНИЯДӘГЕ ХӘЛ ТУРЫНДА „ТАЙМС“ ГАЗЕТАСЫ

ЛОНДОН, 4 гыйнвар. (ТАСС). „Таймс“, Испаниядә гражданнар сугышы моннан 10 ай элек үк беткән булса да төрмәләр элеккечә шыгырым тулы һәм трибуналлар көне-төне эшлиләр дип хәбәр итә. Испаннарны гына түгел, бәлки чит ил кешеләрен дә торган саен күбрәк санда эзәрлеклиләр. Мәсәлән, Мадридтагы Англия—Испания сәүдә палатасының председателе Рей ике тапкыр кулга алынган.

Элек биргән вәгдәләренә дә карамастан, Испания властьлары „политик карашлар буенча“ эзәрлекләүләрне дәвам иттерәләр. Яңадан-яңа каты хөкем карарлары чыгарыла. 50 баск священниккы әле һаман да төрмәдә тотылалар. Тудела һәм Эйбар шәһәрләренең башлыклары, шулай ук баск альпинистларының җитәкчесе атылганнар.



Молотов районындагы 44 нче номерлы балалар бакчасында. РӘСЕМДӘ: сулдан—Роза Сөләйманова, тәрбияче М. Г. Вогинкова, Флера Сарычева һәм Н. Турцевалар аш вактында. Б. Невзоров фотосы.

ГСО значкистларының шәһәр күләмендәге слеты

РОКК ның Татарстан Өлкә Комитеты президиумы 1940 нчы елның 7 нче гыйнварында, кич 6 сәгатьтә, Кызыл Армия йортының колонналы залында ГСО значкистларының һәм РОКК активының санитария-оборона кичәсен оештыра.

Казан шәһәрендәге санитария-оборона активы халыкара хәл һәм Кызыл Хач җәмгыяте активының мобилизацион хәзерлеге турында доклад тыңланачак. Докладтан соң зур художество бүлеге була. Монда хәрби-санитария дружиналары чыгышлары, Кызыл Армия җырлары һәм биюләре, Татрадиокомитет артистларының чыгышлары булачак.

АРЧА КОЛХОЗ-СОВХОЗ ТЕАТРЫ

Арча колхоз-совхоз театры колхозчыларга һәм совхоз эшчеләренә 1939 нчы елда Аблиевнең „Шәмсекамәр“, Фәтхи Бурнашның „Яшь йөрәкләр“ һәм Фатыйх Хөснинең „Урманда“ исемле пьесаларын күрсәтте. Узган елда куелган 220 спектакльне 75 меңгә якын колхозчы-тамашачылар карады.

Театр коллективы колхозларда спектакльләр кую белән бер рәттән, киң күләмдә җәмагат эшләре дә алып барды. Ноябрь һәм декабрь айларында театр тарафыннан 20 урында тамашачылар конференцияләре үткәрелде. Театр җирле Советларга сайлауларга хәзерлек барган вакытта хезмәтчиләре өчен сайлау участкыларында, клубларда түләүсез 20 концерт бирде һәм 14 стена газетасы чыгарды.

1940 нчы елда театр „Күзләр“, „Партизаннар“ һәм „Васса Железнова“ исемле пьесалар куярга хәзерләнә.

ВРАЧЛАР ХӘЗЕРЛӘҮ

Врачларның белемнәрен күтәрү институты (Казан) 1940 нчы елның 1 нче гыйнварына 351 врач хәзерләп чыгарды. Шулар эчендә 113 хирург, 34 педиатор, 43 терапевт, 15 маляриолог һәм башкалар бар. 1939 нчы елда институт барлыгы 2.119 врач һәм сәламәтлек саклауны оештыручылар хәзерләп чыгарды.

Бер үк вакытта институт тарафыннан филиалларда зур фәнни-тикшеренү эшләре үткәрелде. Институтның профессорлары һәм укытучылары 82 тапкыр районнарга чыктылар. Алар Татарстанның район врачларын совет медицинасының яңа уңышлары һәм яңача дәвалау методлары белән таныштырдылар.

СССР КУБОГЫ ӨЧЕН ХОККЕЙ ЯРЫШЛАРЫ

1940 нчы елның хоккей сезоны бик кызыклы булырга вәгъдә итә. Быел СССР һәм ТАССР кубоклары өчен хоккей ярышлары булачак. Ярышларда Казан шәһәренең ирекле спорт җәмгыятьләре катнашалар.

Бүген, 6 нчы гыйнварда бөтен Союз күләмендә СССР кубогы өчен хоккей ярышлары башлана. Ярышлар 28 зонага бүленеп үткәрелә. Казан 16 нчы зонаның үзәге булып тора. Бу зонага Татарстан һәм Удмуртия республикалары керәләр.

Ярышларда Казан шәһәренең иң көчле командаларыннан „Динамо“ һәм „Спартак“ хоккейчылары катнашалар. Кичә „Динамо“ хоккейчылары Ижевский шәһәренә чыгып киттеләр. Алар бүген Ижевскийның „Торпедо“ хоккейчылары белән очрашалар.

12 нче гыйнгарда ярым финаль уеннарында Казанның „Спартак“ командасы Ижевскийда үткәрелгән ярышларда җиңеп чыккан команда белән очрашачак.

***

Бүген шәһәр күләмендә хоккей ярышлары башлана. Ярышлар әйләнмәле системада ике группага бүленеп үткәрелә. Беренче группада шәһәрнең көчле командаларыннан „Динамо“, „Спартак“, „Стрела“, „Наука“ һәм „Азот“ (КХТИ) җәмгыятьләренең командалары уйныйлар. Икенче группада 5 җәмгыять—„Советлар канаты“, Ленин исемендәге завод командасы, „Пламя“, „Локомотив“ һәм „Правда“ командалары катнаша. Һәр җәмгыять беренче группада уйнарга 4 команда, 2 нче группа буенча өчәр команда куя.

Хоккей ярышларында барлыгы 35 команда катнаша. Ярышларда җиңеп чыккан командалар һәм аерым хоккейчылар, февраль аенда Ижевский шәһәрендә үткәреләчәк 9 милли республика спартакиадасына катнашу хокукын алачаклар.

ФИЗКУЛЬТУРА ЭШЕНӘ ӘҺӘМИЯТ БИРМИЛӘР

Ленин районының кайбер предприятиеләрендә спорт-физкультура эше гадәттән тыш начар тора. Профсоюз һәм комсомол оешмалары бу әһәмиятле эшкә бәя биреп житкермиләр. Мәсәлән, 8 нче номерлы кинопленка фабрикасында бер генә пар чаңгы-коньки да юк. 1939 нчы елда спорт-физкультура эшенә дип билгеләнгән 2.500 сум акча башка төрле расходларга тотылган, фабрикада ел буена бер генә кеше дә значкист итеп хәзерләнмәгән. Кышкы физкультура чараларының планы да юк. Комсомол оешмасы (комитет секретаре ип. Ломунов) һәм фабком (председателе ип. Кострев) бу эшне җәелдерү турында уйлап та карамыйлар.

Казкинохимстройда да шундый ук хәл. Постройком янында физкультура инструкторы булса да, ул бер нәрсә дә эшләми.

Спорт-физкультура эшенә мондый игътибарсыз караш бетерелергә тиеш.

А. Овчинников.

„Руслан һәм Людмила“ поэмасы татар телендә

Бөек рус язучысы А. С. Пушкинның „Руслан һәм Людмила“ поэмасы татар теленә тәрҗемә ителеп бетте. Поэманы шагыйрь Әхмәт Исхак тәрҗемә итте. Китап художник Әльминев иллюстрациясе белән чыгарыла.

„Руслан һәм Людмила“ поэмасы (редакторы Г. Разин) Пушкин әсәрләренең яңа алфавитта чыга торган беренче тәрҗемәсе булып тора. Поэма 1940 нчы елның беренче яртысында басылып чыгачак.

ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ ИҖАДИ ДИСКУССИЯСЕ

Язучыларның Г. Тукай исемендәге кабинеты шушы елның 7 нче гыйнварында язучы һәм шагыйрьләрнең иҗади дискуссиясен үткәрә. Бу кызыклы дискуссиядә танкыйтьче Г. Халитнең „Реализммы, провинционализммы?“ дигән темада докладлы куела.

Иҗад кичәсе кич 6 сәгатьтә башлана.

Бер елда 6.012 язу машинасы

Казан язу машиналары заводы коллективы 1940 нчы елны производствода яңа җиңүләр белән каршы алды. Җыю цехы еллык планнан тыш 262 машина эшләп чыгарды. Кою цехы коллективы (начальнигы иптәш Штунь) еллык планны 27 нче декабрьдә 101,7 процент итеп, хәзерләү цехы 128,9 процент итеп үтәде.

Заводның җыю, кою һәм хәзерләү цехлары стахановчылары Әминев, Кузнецов, Исмагыйлев, Халиков, Сафин, Леонов, Моратов, Сердобольский, Гурьянов, Обидин һәм башка иптәшләр еллык планны 150 процентан алып 200 процентка кадәр үтәделәр.

1939 нчы елда завод 6.012 данә язу машинасы эшләп чыгарды. Заводның активы 1940 нчы ел өчен контроль саннарны тикшерде. Быел завод барлыгы 6.030 язу машинасы һәм 200 табулятор эшләп чыгарачак.

АРТИЛЛЕРИСТ СӘЛИМ

(хикәя)

... нче подразделение иртәгә атуга чыгачак. Артиллеристлар барлык материаль частьләрне тагын бер кат тикшереп чыктылар. Сәлим—наводчик, боевой һәм политик хәзерлек буенча отличник артиллерист. Ул иртәгә беренче тапкыр үчын снарядлар белән атачак. Беренче тапкыр, шулай да ул яхшы күрсәткечләр бирүенә ышана. Шуның өчен дә иртәге көнне түземсезлек белән көтә.

Сәлим йокларга яткач та хәтсез вакыт йокыга китә алмый ятты.

Аның иптәшләре арасыннан кемдер аның, йокламыйча, як-ягына әйләнгәләп ятканын ишетте булса кирәк, әкрен генә:

— Сәлим! Саша, Сәлим!—дип эндәште.

Бу кеше частьнең күренекле артиллеристы Коля Демин иде.

— Коля, син дә йокламыйсыңмени?

— Саша, синең вазелинең бармы? Борынны әйтәм әле, кояшта пешкән яшь бәрәңге кебек, тоткан бер җирдән куба. Җитмәсә әрни тагын...

— Мин сине иртәге көн турында уйлысың дип торам. Әнә, тумбочкада, одеколон артында.

— Менә рәхмәт. Ә син нигә йокламыйсың?

— Мин, тынгысыз охотник шикелле, иртәгә „аю“ның кайсы төшенә тигезергә, дип уйлап ятам.

— О, Сәлим, тиресен бозмаслык итеп күзенә тигезәчәкбез.

Кояш чыгып, таулар һәм урманнар өстенә таба күтәрелеп барганда Сәлимнәр юлда иделәр инде. Колонна тавышсыз хәрәкәт итә. Командалар ярым тавыш белән генә биреләләр. Артта поход кухняләреннән төтен баганалары күтәрелә.

Иртәнге сәгат бишләрдә „дошманның“ хәрәкәте турында беренче хәбәрләр килә башлады. „Дошман“ ягыннан винтовкадан һәм пулеметтан аткан тавышлар ишетелә башлады, озак та үтмәде орудие тавышы да яңгырады.

Сәлимнәр подразделениесе исемсез тау итәгенә урнашырга, „дошман“ атакасын кире кагарга һәм аны юк итәргә приказ алды.

Орудиеләрне огневой разъезд билгеләнгән урыннарга тиз арада тәгәрәттеләр, дошман күрмәслек һәм ату өчен җайлы итеп урнаштырдылар. Командир өчен күзәтү пункты төзелде—зур төгәллек белән күзәтергә мөмкинлек бирә торган приборларның объективлары дошман пунктларын күзәтә башладылар. Вычислительләр ут ачу өчен кирәкле саннарны хәзерләделәр. Алар, өлгер математик шикелле, артиллерия ату теориясенең тиешле формулаларыннан оста файдаланып, кирәкле саннарны нормадан иртә өлгерттеләр. Разведчиклар „дошман“ ның яңадан-яңа пунктларын ачтылар, аларны үзләренең топография карталарына төшерделәр. Һәрбер артиллерист хәрәкәтендә эшчәнлек һәм үз эшен оста белгәнлек күренеп тора.

Сәлимнәр расчеты орудиене иң алда хәзерләп бетерде. Орудие командиры прицел һәм башка установкаларның дөреслеген тикшерде,—новодчик үз эшен оста башкарды.

— Яхшы, иптәш новодчик. Команданы диккат белән тыңлагыз.

Есть, иптәш командир, команданы диккат белән тыңларга!

Бары да хәзер. Барсы да үз урнында. Командир пункттан алынган команданы тулы хәзерлектә көтеп тора.

Телефонист беренче команданы тапшырды:

— „Дошман“ батареясенә!

— Фугаслы граната белән!.. Угломер... Уровень... Прицель... Огонь!

Сәлим приборларны тиешле бүлемнәргә тиз һәм төгәл итеп куйды. Беренче ату яңгырый. Совет артиллерия яңгырының берничә килограм авырлыгындагы метал тамчысы, дәһшәтле сызгырып, „дошман“ ягына очты. Орудие алдындагы үләннәр, курыккандай булып җиргә постылар. Еракта снаряд шартлады. Тузан белән катнаш, төтен баганасы күтәрелде...

— Сулгарак 0-05!

Икенче ату, өченче ату, дүртенче... Еракта кук кукрәгән шикелле. Тузан-төтен баганалары бер-берсенә тоташтылар. „Дошман“ батареясе макетлары, йомычкага әйләнеп, өскә күтәрелделәр.

Телефонист командирның кыска һәм ачык командасын тагын тапшырды:

— Пулемет оясына! Ватыклы граната белән! Угломер... Прицель...

Озак та үтми, разведка, „дошман“ группасының атакага юнәлгәнен хәбәр итте. Күп көттерми, урман почмагыннан танклар килеп тә чыктылар.

— Туры төзәү белән, „дошман“ танкларына!

—Ут! дигән команда алына.

— Күзенә, Сәлим, күзенә!

— Күзенә, Коля!

Шартлаулар тагын җирне тетрәттеләр. Көчле эхо бер таудан икенче тауга сикерде. Хәрәкәт итүче танк макетлары бер-бер артлы, чәлпәрәмә килеп, читкә чәчрәделәр. „Дошман“ атакасы кире кагылды. Пехота һөҗүме белән „дошман“ тәмам тар-мар ителде.

Танкларга каршы атудан да иң яхшы күрсәткечне Сәлимнәр расчеты бирде, — 38 секунд эчендә 4 атып, 3 туры тигерү ясады. Ныклы теоретик хәзерлек, барыннан да бигрәк, совет патриотизмы үзенең гүзәл нәтиҗәләрен бирде. Бездә халык шатлыгы һәм тынычлыгы өчен булган һәрбер эш үзенең тиешле бәясен таба. Сәлимнәр расчетына да подразделение командиры капитан Мощерев, яхшы эшләре өчен рәхмәт белдерде.

Совет иленең изге җиренә аяк баскан дошманның язмышы хурлык һәм җиңелү белән бетәчәк! Бүгенге репетиция тагын бер тапкыр әнә шуны күрсәтә.

Сәлим казармаларга кайтканда, Байкал артының киң кырларын, матур урманнарын соклана-соклана күзәтеп кайтты. Янында утырып кайткан Коля белән:

„Иркен дә соң минем туган илем,
Урманы күп аның, җире, суы күп...“

дип тирә якны яңгыратып җырлап та алдылар. Төрле төстәге чәчәкләрнең хуш исләре хәтернең эчкәрәк урыннарын кытыкладылар. Үткән ел, нак шушы вакытта диярлек, Вахитов исемендәге комбинатның стахановчылары маевкасында сөйгән кызы Суфия белән шундый ук чәчәкләрдән букет ясаганнарын, маевкадан кайтканда, өйрәнүдән кайтучы кызыл армеецләргә очрап, ул букетны бер артиллеристка бүләк итүләрен хәтерләде. Ул вакытта орудиедә атуның теориясен белү түгел, пушкаларның төрләрен дә аера белмәгәне дә хәтеренә килде. „Әгәр Суфия мине хәзер күрсә, минем инде шулай ярыйсыгына атуымны да белсә, берне генә түгел, миңа ике букет бүләк итәр иде“ дип уйлады.

Кызыл армеец *Фасеев.*

Байкал арты хәрби округы.

Җаваплы редактор
Һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.

Галиәсгар Камал исемендәге
Татар Дәүләт Академия театры
6 нчы гыйнварда көндез
КҮЗЛӘР
Талон 89.
Кич, шулай ук 7 һәм 8 нче гыйнварда
КЫЮ КЫЗЛАР
Бүген кич талон 90.
Спектакль кич 7 сәгат 30 минутта башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
Бүген, 6 нчы гыйнварда көндез һәм кич
ПАВЕЛ ГРЕКОВ
Талоннар: көндез 15, кич 70.
Спектакльләр кич 7 сәгат 30 минутта башлана.
Билетлар көндез 11 сәгат 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 8 сәгат 30 минутка кадәр кассада сатыла.
КАНИКУЛ КӨННӘРЕНДӘ
6, 9 һәм 12 нче гыйнварда көндезге спектакльләргә коллектив заявкалар буенча килүчеләргә (100 билеттан ким булмаганда) 50 процент ташлама ясала.

Киров районындагы
Культура сарае
6 нчы гыйнварда көндез һәм кич
БАКЧАЛАР ЧӘЧӘК АТА
Талоннар: көндез 40, кич 41.
Спектакль кич сәгат 8 дә башлана.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
Тулысынча яңа программа
Москва 4 нче труппасының гастрольләре.
ЯҢА ЕЛ КАРНАВАЛЫ
Бөтен труппа катнаша.
Орденлы АЛЛИ-ВАД ның һәм ВЕРА МИРОВАНЫҢ соңгы гастрольләре.
12 нче гыйнварга кадәр һәр көн 11 сәгатьтә, 2 сәгат 30 минутта һәм кич 8-дә
ЦИРК УЕННАРЫ
Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 1 гә һәм кич 5 тән 8 гә кадәр ачык.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО“ 10, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Көндез 10 сәгатьтә ХӘЗИНӘЛӘР АТАВЫ һәм башка сеансларда ПАРТБИЛЕТ
„УНИОН“ 12, 2, 4, 6, 8, 10 да.	УКЫТУЧЫ Көндез 10 сәгатьтә балалар өчен сеанс
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ“ 11, 1, 3, 5, 7-30 һәм 10 да	Көндезге сеансларда АЛТЫН АЧКЫЧ Кич БӨЕК ГРАЖДАНИН (икенче сериясе)
„ЧАТКЫ“ 6, 8 һәм 10 да.	ЦИРК
„ПИОНЕР“ 6, 8 һәм 10 да	Көндез һәм кич ҺАВА ПОЧТАСЫ Көндез 1 сәгатьтә мәктәпкәчә тәрбия яшендәге балалар өчен сеанс ВАРЯ КАПИТАН
„РОТ-ФРОНТ“ 10, 12, 2, 4, 6, 8, 10 да.	СОРОЧИНСКАЯ ЯРМАРКА
„КОЛХОЗНИК“ 6, 8 һәм 10 да	БАЛТЫЙКЧЫЛАР
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7 һәм 9 да.	СЕНТЯБРЬДӘГЕ ТӨН

Татарстан АССР Совнаркомы янындагы Автоуправлениенең
бензин һәм майлау материаллары конторасы
шәһәрдәге һәм районнардагы бензин алучыларның кулларындагы
ТАЛОННАРНЫ ТЕРКӘҮ ҮТКӘРӘ
Шәһәрдәге бензин алучыларның талоннарын теркәү шушы ел 8 нче гыйнварга, ә районнардагы бензин алучыларның талоннарын теркәү 13 нче гыйнварга кадәр дәвам итә.
Бензин һәм майлау материаллары станциясенең Автотранспорт наркоматына күчерелүе унае белән, күрсәтелгән срокта теркәлмәгән талоннар гамәлдән чыккан дип исәпләнәчәк.
Бензин талоннарын теркәтергә килүчеләрдән ышаныч кәгазе сорала. 5—3—1

КАЗАН ДӘҮЛӘТ
СЕЛЕКЦИЯ СТАНЦИЯСЕ
Дәүләт учреждениеләренең һәм частный кешеләрнең ишек алларында ат, сыер, дуңгыз, кош-корт асрау урыннарында җыелган һәм башка төрле
ТИРСЛӘРНЕ,
теләсә нинди күләмдә булуга карамастан,
БУШЛАЙ АЛЫП КИТӘ
Тиреснең кайда булуын һәм аны кайчан алып китәргә мөмкин булуын түбәндәге адрес буенча белдерергә: Казан, почта ящиге № 8, Дәүләт Селекция станциясе. Телефон 3—27.
9—4

КИРӘК:

Казан Мехкомбинаты идарәсенә КВАЛИФИКАЦИЯЛЕ МАШИНИСТКАЛАР. Яңа бистә, Кызыл Татарстан урамы, 3, бүлмә № 13. 2652—5—4

Татарстан АССР Совнаркомы янындагы юллар идарәсенә, ЯШЕЛЛӘНДЕРҮ һәм КАР БАСУДАН САКЛАНУ ЭШЛӘРЕ БУЕНЧА ИНЖЕНЕР. Хезмәт хакы килешү буенча. Казан, Островский урамы, 2. 2695—2—2

Главлегснабның Казан конторасына СЕКРЕТАРЬ-МАШИНИСТКА, химикатлар хәзерләү буенча ТОВАР БЕЛГЕЧЕ һәм өстәмә хезмәт рәвешендә эшләү өчен ЮРИСКОНСУЛЬТ. Көндезге 4 сәгаттән 5 кә кадәр Главлегснабка килергә. Казан, Кече Ямашев урамы, 71. 4—2—1

Казан автомәктәбенә УКУ-УКЫТУ БҮЛЕГЕ ӨЧЕН МӨДИР һәм АВТО ЭШЛӘРЕ ТЕОРИЯСЕ БУЕНЧА УКЫТУЧЫЛАР. Казан, Кызыл Армия бистәсе, Красный Химик урамы, 19. Мәктәп № 49. 2683—2—2

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 202. ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА ДОМ ПЕЧАТИ. 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 78.